КАДЕРЛЕ ИПИ

Казанның данлыклы 3 нче икмәк пешерү заводында эшләүчеләр яхшыга өметләнә

> 2

ПЕКИНГА ЮЛЛАМА

Россиянең хоккей җыелма командасына «Ак барс»тан ике уенчыны чакырдылар

> 4



КЕЧКЕНӘ ДӘ ТӨШ КЕНӘ

Быел «Балалар премиясе»нә кемнәр лаек булды?

> 4

РӘХМӘТ, ТАБИБ!

22 яшендә күпләр өчен иң кирәкле кешегә, зарыгып көткән берәвенә әйләнә Инзилә Зәкиҗанова

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 10 (28783) | Сишәмбе | 25 гыйнвар | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

КАРЛАР ЯУСЫН ТЫН ГЫНА...

Быел карны көрәп бетерә торган түгел. Авылда яшәүчеләр әнә шулай ди. Шәһәрдә дә кимен куймый. Юлларны чистартырга техника җитәме? Кар күмеп, өеннән чыга алмаучылар юкмы? Ә синоптиклар алдагы көннәрдә дә явым-төшем фаразлый.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Хөкүмәт йортында узган республика киңәшмәсендә Президент Рөстәм Миңнеханов район һәм шәһәр башлыкларына карны җыештыруны контрольдә тотарга кушты.

– Кар күп яугач, юлларны карап тоту сыйфаты начарайды. Олы юлда да, торак пунктларда да. Социаль челтәрләрдә зарланып язучылар 5 мәртәбә артты. Шикаятьләрнең яртысы юлларны чистартуга бәйле, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Мин аңлыйм, без беренче чиратта олы юлларга игътибар итәбез, әмма ишегаллары буенча да зарлар күп. Мәктәп маршрутлары, гадәттән тыш хәлләр, санитар транспорт өчен юлларны ачу – болар контрольдә булырга тиеш. Транспорт министрлыгына юлчыларда булган техниканы эшкә җигәргә кирәк.

Мөрәҗәгатьләрнең күбесе Алабуга, Питрәч районнарына, шулай ук Казан, Чаллы, Түбән Кама, Бөгелмә, Әлмәт шәһәрләренә кагыла. Урамнарны җыештыруда төп проблема – ишегалды җыештыручыларның хезмәт хакы аз булу, эшче куллар җитмәү. Казанда шәһәр урамнарын җыештыручы тракторчы-машинистларның хезмәт хакларын 60 мең сумга кадәр арттырганнар. «Горводзеленхоз»да эшләүчеләрнең уртача хезмәт хакы 55–60 мең сумны тәшкил итә.

Кар ишеп яуган буранлы көннәрдә бигрәк тә кечкенә авылларда ялгыз яшәүчеләр искә төшә. Ашарга-эчәргә тилмереп ятмыймы икән дип, Кукмара районы Тәмле Чишмә авылында яшәүче 81 яшьлек Нурулла ага Гайфетдиновның хәлен белешергә булдык.

– Кар тирән, кеше юк, кибет тә, медпункт та юк... Һич югы, бер генә күрше булса икән. Шушы шартларда авылда ялгызым яшәп ятам. 15 ел буе кышын бер үк хәл. Бу тормышка ияләштем инде. Хатыным кыш көне шәһәрдә яши. Йөрәге авырта, авылда яшәсә, мин аны ничек хастаханәгә алып барыйм? Быел кар тагын да күбрәк яуды. Чаңгы белән йөреп булмый, бата. Зарланып әйтүем түгел, үзем сайлаган язмыш. Монда берәү дә минем өчен генә юл ачып йөрми. Сукмак салсаң да, буран күмеп китә. Шуңа кар көрәүдән мәгънә күрмим. Боттан гына ерып йөрү түгел, кар көртләре башка кадәр җитте хәтта, – ди Нурулла ага. – Бер көнне кар явып, икенче көнне катырса, сөенәм. Ул вакытта чишмәгә чаңгы белән барып була. Коеның суы бетте. Елгага төшеп, каткан чишмә янындагы чокырдан суны чүмеч белән тутырып кайтам. Әле ярый Кукмарадан егетләр карчанада ял итәргә килә. Алар азмы-күпме юл салып китә. Ипи, сөт, прәннеген алып килә. Күрше авылга алты чакрымдагы кибеткә бернichек тә бара алмыйм. Шуңа күрә ризык запасын күбрәк туплап куям. Өйдән чыга алмыйча яткан чаклар бервакытта да булмады.

Балык Бистәсенең Кызыл Йолдыз авылында бүген 37 хуҗалык исәпләнә. Бу авылда да кибет юк. Сатучысыз кибетләре һаман да эшләми икән. Котлы Бөкәш авылына барып, кирәк-ярakларын шуннан алып кайталар. Лариса Кибякова әйтүенчә, юлны урман хуҗалыгы тракторы ачып тора.

– Яуган вакытында ук булмаса да, кичкә урамнар ялт итә. Кар бик күп быел. Түбәдән төшеп тора, әле теплица кырыйларын ачып кердек. Вәт әкәмәт, өстендә берәр метр кар ята. Көрәмәсәң, теплицаны сытачак. Көн саен көрибез. Юл ябылып, чыга алмыйча калган чаклар юк, – ди Лариса. – Икенче яктан, кар явуның нәрсәсе гаҗәп инде аның?! Гадәти хәл бит инде ул. Кеше хәзер артык нәзберекләнде. Бераз кар яву да зур мәшәкать тоела аңа.

Чирмешән районының Лашман авыл җирлегендә буранлы көннәрдә таракторчы егетләр иртәнге сәгать 2дә үк торып, юлны чистарткан. Авыл җирлеге башлыгы Рәвгать Фәттахов: «Шикаять язучы юктыр бит? Юлны чистартып торабыз. Беренче чиратта янгын частен, мәктәп-бакча тирәсен кардан арындырабыз», – ди. Аның әйтүенчә, быел кар узган елга караганда күбрәк яуган. Былтыр грант отып, тагын бер трактор алганнар. Ике авылга – ике трактор. Көчле бураннарда да бернинди өзеклек булмаган. «Үзара салым акчасына ягулык алабыз, тракторчыларга хезмәт хакы түлибез. Үлем-китем, туй яки башка мәҗлесләр булган очракта капка төпләрен ачарга булышабыз. Ялгыз яшәүче әбиләргә дә ярдәм итәбез», – ди ул.

Шәһәрдә яшәсәк тә, Питрәч районының Көек авылындагы йортыбызга көнаралаш кар көрәргә барырга туры килә. Моңа кадәр урамга машина белән ничек тә керә идек әле, ә бу юлы юлны бөтенләй ачмаганнар. Көрәкләрне күтәреп, кире кайтып китәсе килмәде инде. Карда бата-чума җәяүләп бардык. Күрше урамда яшәүчеләр дә, юлны үзебез чистартабыз, дип зарланышып алдылар. Бер мәртәбә кар ерудан зыян булмас анысы, икенче юлы тагын шундый хәл кабатланса, туйдыра башлаячак бит.

– Зарланмасыннар, чистартып торабыз бит. Мөмкинлеккә карап тырышабыз. Ул юлларны да ачарбыз, – диде Питрәч районының Богородское авыл җирлеге башлыгы Марс Бикбов.

Сәрия МИФТАХОВА

Студентның юлына акча бар

Татарстанда 6 меңгә якын студентка җәмәгать транспортында йөрүгә грант биреләчәк. Кайберәүләр әлеге акчаны алган да инде. Бу хакта яшьләр эшләре министры урынбасары Суфия Мостафина белдергән. Быел Татарстанның «Транспорт гранты» проектына 60 миллион сум бүлеп бирелгән. 2019 елдан соң акча күләме инде ике тапкыр арттырылган. Конкурсны узганнан соң студентларга карта бирелә, соңыннан аңа билгеле бер күләмдә акча килә. Казан өчен грант күләме – 11 мең сум.

Грантка дәгъва кылу өчен гел «бишле»гә укырга һәм социаль тормышта актив катнашырга кирәк. Киләсе елда грантны үстерү һәм киңәйтүгә исәп тотыла.

Чаллыда өй туйлары уза

Кичә Чаллы шәһәренең 63 нче микрорайонында 216 фатирлы торак йортка күченү тантанасы булды. Анда бюджет оешмалары, предприятиеләр хезмәткәрләре, грант откан медицина хезмәткәрләре һәм яшь гаиләләр яшәячәк.

Социаль ипотека программасы буенча төзелеп, быел файдалануга тапшырылган тәүге йорт 10 катлы, 6 подъездлы. Гомуми мәйданы – 13310 кв. м. 18 фатиры – бер бүлмәле, 108е – ике, 90ы – өч бүлмәле. Фатирларның барысы да яшәү өчен тулысынча әзер: сантехника, исәпләгечләр, кирәкле датчиклар белән тәэмин ителгән. Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды директоры Марат Зарипов әйтүенчә, фонд 63 нче микрорайонда 2017 елда торак төзи башлаган. Монысы инде – социаль ипотека буенча төзелгән тугызынчы йорт. Хәзер микрорайонда 2555 гаилә яшәячәк. Биредә әлеге программа нигезендә тагын 4 йорт төзелеп килә.

Каникулда чыгым күп китә

Яңа ел бәйрәмнәрендә Казан халкы гадәттәгедән күбрәк акча тоткан. Эш эзләү сайты үткәргән тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, каникул вакытында башкалабызда яшәүчеләрнең 68 процентының чыгымы арткан. Сораштыру йомгаклары буенча, респондентларның 35 проценты бәйрәм көннәрендә акчаны гадәттәгедән күбрәк исраф иткән. Сораштыруда катнашучыларның 24 проценты чыгымнарны каплау өчен хәзер акчаны кысыбрак тота башлаган, 35 проценты кыйммәтле әйберләр сатып алуны кичектергән, 23 проценты өстәмә эш алган яки алырга тели икән. Күпчелеге акчаны якыннары һәм туганнарына бүләккә, шулай ук ял итү, күңел ачуга сарыф иткән. Тулаем алганда, ил буенча бүләк алуга тотылган акча күләме 2–6 мең сум аралыгында тибрәлә.

Сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Казан халкының 71 проценты Яңа ел бәйрәмнәрен өйләрендә фильмнар яки сериаллар карап уздырган. 67 проценты – туганнары һәм дуслары белән очрашуларны, 64 проценты урамда саф һава сулап йөрүне хуп күргән, 12 проценты сәяхәткә юл тоткан.

Өстәмә турында Пенсия фондыннан белешәсе

Соңгы көннәрдә интернет челтәрендә «совет чорындагы эш стажы өчен» пенсияне арттыру турында хәбәр таралды. Янәсе, шушы вакытка өстәмәне алу өчен Пенсия фондына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Әмма әлеге мәгълүмат дөреслеккә туры килми, дип хәбәр итә Пенсия фондының Татарстандагы бүлеге.

Исегезгә төшерәбез: 1991 елга кадәр эш стажына ия булучыларның пенсиясе 2009 елда арттырылды. Ул чагында Пенсия фонды бүлеге белгечләре 2010 елга кадәр билгеләнгән барлык пенсияләрне яңадан исәпләде. Шуннан бирле пенсияләр совет чорындагы эш стажыннан чыгып билгеләнә.

Гадәттә мондый өстәмәләрне нindидер юридик ширкәтләр вәгъдә итә. Алар өлкәннәргә гаризалар рәсмиләштерүдә булышырга тәкъдим итә. Әлбәттә инде, бушлай түгел. Мондый ширкәтләр, чыннан да, Пенсия фонды бүлегенә хат юлларга мөмкин. Әмма аларга, «совет чорындагы эш стажы» өчен өстәмә түләнгән, дигән аңлатма гына җибәрелә. Нәтиҗәдә пенсионер юридик ширкәткә акчасын юкка гына түләгән булып чыга.

Игътибар! Пенсия фонды барлык хезмәтләрне бушлай күрсәтә. Сорауларыгыз булса, аңа шәхсән мөрәҗәгать итәргә, яки 8-800-6-000-000 бушлай телефоны аша элемтә үзәгенә шалтыратырга кирәк.

COVID-19

Чакырылмаган кунак

БЕР ТӘҮЛЕК ЭЧЕНДӘ ТАТАРСТАНДА КОРОНАВИРУС ЙОКТЫРУЧЫЛАР САНЫ 1,5 ТАПКЫР (!) АРТКАН

Курыкканга куш килә башлады. Бер тәүлек эчендә илдә коронавирус йоктыручылар саны 65 меңнән артып китте. Белгечләрнең коронавирусның «омикрон» штаммы алдагыларыннан күпкә йогышлырак, вирусның чираттагы дулкыны аеруча авыр узачак дигән фаразлары чынга аша башлады булса кирәк.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, соңгы бер тәүлек эчендә республикада 213 кеше коронавирус йоктырган. Шуларның 36сы хастаханәдә ятса, калганнары өйдә дәвалана. Авыру очракларының күбесе Казанда теркәлгән. Шул рәвешле пандемия башланганнан бирле ковид белән авыручылар саны 45528гә җиткән. Ил күләмендә бу сан 11 миллионнан артып китте.

Белгечләр коронавирусның яңа «омикрон» штаммы алдагыларыннан күпкә мәкерлерәк дип кисәтә. Күп очракта ул кешедә бернинди билгеләрсез генә дә узарга мөмкин, ди алар. Әмма соңгы арада галимнәр фәкать яңа штаммга гына хас булган үзгә билгеләрне дә ачыклый башлаган. Билгеле булганча, коронавирус вакытында кеше, иң беренче чиратта, ис һәм тәм сизми башлый. Һәрхәлдә ковидның алдагы штаммнары вакытында чир еш кына әнә шулай башлана иде. «Омикрон» йоктырган кешедә исә бу билгеләр, гомумән, күзәтелмәскә мөмкин икән. ДНКОМ молекуляр-генетик тикшеренүләр фәнни үзәге башлыгы Андрей Исаев бу көннәрдә «омикрон» штаммы организмга күзләр аша да үтеп керә ала дигән белдерү белән чыкты. «Коронавирусның әлеге штаммын йоктырган кешедә еш кына конъюнктивит башлана. Димәк, ул организмга күзләр аша да үтеп керә ала», – ди белгеч.

Балаларда исә ул бронхит, эч китү кебек билгеләр белән узарга мөмкин дип кисәтәләр. Татарстанга балаларга коронавируска каршы ясала торган «Спутник М» вакцинасының беренче партиясе кайтты. Ул 2880 дозадан тора. Татарстанның баш эпидемиологы Александр Лопушов сүзләренә караганда, бу көннәрдә аны хастаханәләргә таратачаклар. Ел дәвамында исә Татарстанга 200 меңнән артык доза «Спутник М» вацинасы кайтыр дип көтелә. Яңа вакцинаны 12–17 яшьлек үсмерләргә ясарга җыеналар. Хәзерге вакытта республиканың белем бирү оешмаларында укучы балаларның әти-әниләреннән коронавируска каршы прививка кадатуга рөхсәт язуы җыялар. Риза булучылар прививканы бу атнада ук кадата алачак. Сүз уңаеннан, хәзерге вакытта республикада барлыгы 2357399 кеше коронавируска каршы прививка ясаткан. Кабат вакцинация узучылар 173239 кеше.

Президент Рөстәм Миңнеханов атна ахырында Хөкүмәт йортында узган утырышта республика сәламәтлек саклау тармагының коронавирус белән вазгыять катлаулануга әзер булуын искәртте. «Коронавирус белән авыручылар саны кисәк артты. Ләкин стационарда ятучылар саны алай ук күп түгел. Шулай да, вазгыять катлаулана калса, ятак урыннар саны өч тапкыр арттырылачак», – дип белдерде Рөстәм Миңнеханов. Медицина җиһазлары белән даруларның да контрольдә булуын искәртте ул. Президент сак булырга кушты.

Авыручылар саны артса да, «омикрон» штаммы аркасында илдә локдаун игълан итәргә җыенмыйлар. «Авыручылар саны арта, әмма хастаханәдә ятучылар саны артмый. Локдаун кертелү турында сөйләшүләр алып барылмый», – дигән Россия Президентының матбугат сәркатибе Дмитрий Песков.

Сүзгә-сүз

Рөстәм ГАФАРОВ, Казан Башкарма комитеты җитәкчесе:

Пандемия белән бәйле рәвештә, бизнеска җиңелрәк булсын өчен, штрафларга мораторий керттек. Әмма пандемия – тәртипсезлек өчен сәбәп түгел. Без эшмәкәрлеккә ярдәм итәргә телибез, ләкин бу әле иркенәергә мөмкин дигән сүз түгел.

ТАТАРСТАН ХАЛКЫНЫҢ БАНКТА КҮПМЕ МАЯСЫ САКЛАНА?

Татарстанның Милли Банкы мәгълүматларына караганда, республикада яшәүчеләр 712 млрд сум акчасын (эскроу-счетларны да кертеп) банкларда саклый. Ел дәвамында әлеге сумма 10,8 процентка арткан.

Рубльдә (84,2%)
599,3 млрд сум – **8,9 процентка** арткан.

Чит ил валютасында (15,8%)
112,6 млрд сум – **22,1 процентка** арткан.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

«ОМИКРОН»НАН КЫЗЫЛ УТ

Дөнья сәясәтендә дә, глобаль икътисадта да вакыйгалар зур сикәлтә өстендә биюен дәвам итә. «Би-би-си»нең дүшәмбе иртәсе чыгарылышы «Европа Россия газыннан башка туңа» дип исемләнгән баш мәкалә белән ачыла. Көнбатышлылар газ сугышы турында сүз алып баралар, халыкны һәм сәнәгатьне коткару өчен ярымхәрби план әзерләүләре турында әйтәләр.

АКШның дәүләт департаменты Украинадагы илчеләргә аннан китәргә рөхсәт бирде. Гади халыкка да ул илдән качарга һәм Россиягә бармаска киңәш ителә. Киеренкелек, әле сугыш дәрәҗәсенә җитмәгәндә дә, безнең тормышны агулый: үткән атна уртасында бераз күтәрелә башлаган Россиянең фонд базары җомга көнне тагын түнде, доллар курсы сикерде. Американың фонд базарларында да салмак түбәнәю бара. Британия миллиардеры Джерми Грэнтэм АКШта «дүртенче супер куык» шартлап, кыйммәтле кәгазьләрнең 50 процентка очсызланачагын фаразлый.

Шундый күңелсез яңалыклар фонында автомобиль җитештерүчеләргә конвейерларны хәрәкәткә китерергә «омикрон» комачаулый дип чаң сугалар. Автомобиль заводлары үткән ел ук, микрочиплар җитешмәү сәбәпле, бик еш тукталып, ябылып торганнар иде. Быел хәл тагын да җитдирәк дип әйтәләр, чөнки комплектлаучы детальләр дефицитына эшче куллар җитешмәве килеп кушылды. Персонал чирнең кискен таралуы сәбәпле эшкә чыкмый. Үткән атнада Японияда авырулар саны рекорд куйды. Toyota илдәге 14 заводының унберендәге 21 җитештерү линиясен туктатырга мәҗбүр булды. Ярымүткәргечләр җитешмәү аркасында болай да гыйнвар аенда машина чыгару 20 меңгә кимрәк буласы иде. «Омикрон» бу санга үз төзәтмәсен кертте. Хәзер инде яңа автомобильләр җитештерүнең гыйнвар планы 47 мең машинага кимрәк үтәләчәк. «Toyota»ның яңа чыга башлаган кайбер популяр модельләренә чиратны дүрт ел көтәргә туры киләчәк, диләр.

Башка япон автобрендлары да кыенлык кичерәләр. Honda, Nissan һәм Suzuki заводларында эшче кулларга кытлык алай ук зур түгел икән түгелен. Әмма аларга комплектлаучы детальләр җитештерүчеләр эшкә кеше таба алмыйлар. Нәтиҗәдә әлеге өч компания куәтләренең 70–90 процентына гына эшлиләр.

«Омикрон» автомобиль сәнәгате кризистан чыгам дип торганда гына көпчәкләр астына килеп керде. Үткән елның ноябрендә автомобиль җитештерү 40 процентка артып, күнегелгән колеяга керә башлаган булган. «Омикрон»нан башка да автомобильчеләрне икътисади үсешнең түбәнәюе дигән проблема көтеп тора. Микрочиплар җитешмәү дигән киртә дә беркая китмәде. Элек электрон системалардан башка гына чыгарыла торган гадирәк машиналар да хәзер ярымүткәргечләр сорый, ә аларны җитештерүне тиз генә арттырып булмаячак. Яңа җитештерү мәйданнарын корып эшкә җиккәнче айлар таләп ителәчәк, диләр белгечләр.

«Омикрон» турында яхшы хәбәрләр дә бар. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасының Европа бүлеге җитәкчесе Ганс Клюге бу уңайдан: «Пандемия финалына якынлаша», – ди.

Россиядә

УҢЫШ КИМ БУЛЫРМЫ?

Россиядәге вазгыять тә дөньядагы хәлләргә туры пропорциональ бәйлелектә үзгәрә. Базарлар арасындагы тыгыз элемтә, Җир шары масштабындагы хезмәт бүленеше һәм товар алмашу үзенчәлекләре бер илдәге проблемаларны бик тиз башкалар өчен дә зур мәшәкатькә әйләндерә.

Белгечләр 2022 ел уңышы түбән булыр һәм азык-төлеккә бәяләр тагын да үсәр дип фаразлый. Бигрәк тә бәрәңге һәм шикәр бәясе зур сикереш ясарга мөмкин икән. Әле урамнарда мул булып кар яуганда, без югарырак уңышка өметләнәбез өметләнүен. Вәләкин хәлләрне нечкәлекләре белән белүчеләр алдагы җәйдә үсемлекләрне корткычлардан һәм авырулардан саклау чаралары – химикатлар дефициты яный дип белдерә. Пестицидлар булмадымы, уңышның 10 проценттан 60 процентка кадәре югалачак, ди алар. Күз алдыгызга китерегез инде: колорадо коңгызына каршы агу сипмәсәк, бәрәңге уңышы нинди булачак? Йөз процентка якыны юкка чыгачак.

Агулар мәсьәләсендә без нигездә һаман да шул Кытайга бәйле икәнбез. Күк асты илендә исә экологияне кайгырта башладылар. Табигатькә зыянлы товарларны җитештерүне киметү сәясәтенә күчтеләр. Димәк, ашламалар гына түгел, корткычларга һәм чүп үләннәргә каршы чаралар да җитешмәячәк. Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы инде агрокультуралар өчен кирәкле бу товарлар белән тәэмин ителешне тикшерә башлаган. Химикатлар белән тәэмин ителеш мәсьәләсен вакытында хәл итү юллары эзләнә. Аларны башка базарлардан кайтарту юллары өйрәнелә.

Авыл хуҗалыгы министрлыгының 13 гыйнвардагы утыршында нәкъ шул хакта сүз барган. Үсемлекләрне саклаучы химик матдәләр җитештерүчеләрнең Россия берлеге, аларны җитештерү өчен кирәкле чималның бәясе күтәрелү һәм транспорт чыгымнары арту сәбәпле, гербицидлар бәясе үсү ихтималы турында да кисәтте. Авыл хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматлары буенча, бәя үсү 20 проценттан 80 процентка кадәр булырга мөмкин икән. Андый бәя үсешен авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре җилкәсе күтәрә алмавы һәм гербицидлар куллануның кимүе ихтимал. Хәлләр шул юнәлештә хәрәкәт итсә, чәчелгән ашлыкны саклап калу мөшкел булачак. Гербицидлар өчен кирәкле актив матдәләрнең 60 процентка якыны – Кытайдан, калганы башка базарлардан алына, алар бездә синтезланмый, ди белгечләр. 2021 ел ахырына ук инде аларга бәяләр 2020 ел белән чагыштырганда 1,5–2 тапкыр арткан. Кытай «яшел» сәясәт уздыра башлады һәм бу дөньякүләм химикатлар базарында бәяләрнең озак сроклы үсешен китереп чыгарачак. Җитмәсә Кытайга алмаш базарлар юк, чималны башка җирдән китертү мөмкин түгел диярлек.

Гербицидларсыз гына иген игү басуларны чүп басуны һәм корткычлар котырынуын вәгъдә итә, уңышны нык киметә. Болай да түбән булган рентабельлек бөтенләй юкка чыгачак. Химик матдәләрне үзебездә синтезлый башлау өчен күп вакыт һәм инвестицияләр таләп ителә, бездә җитештерелгәне Кытайныкыннан арзан булыр дип әйтеп тә булмый. Әлегә хәл шундый, чишелешне җәй һәм көз күрербез, Аллаһ теләсә.

УРТАК ЭШ ДӘВАМ ИТӘЧӘК

Рөстәм Миңнеханов Казахстанга сәфәр кылды. Президент Касыйм-Җомарт Токаев һәм яңа Премьер-министр Алихан Смаилов белән очрашуларда уртак эшләрне дәвам иттерү, хезмәттәшлекне үстерү турында фикер алыштылар.

tatarstan.ru

Касыйм-Җомарт Токаев фикеренчә, Россия белән күпкырлы үзара мөнәсәбәтләрдә Татарстан мөһим урын алып тора. Узган елның 11 ае нәтиҗәләре буенча ике арадагы товар әйләнеше 423 млн долларны тәшкил иткән. Очрашуда яклар уртак проектлар буенча фикер алышты. Сөйләшүләр барышында «Татнефть» һәм КамАЗның генераль директорлары хәзерге вакытта гамәлгә ашырылып килүче проектлар турында сөйләде һәм үзләренең юнәлешләре буенча алга таба хезмәттәшлек итү мөмкинлекләре белән таныштырды. «Илдә хөкүмәт алышынса да, дәвамчанлык сакланып кала һәм Казахстан җитәкчелеге алга таба да КамАЗ һәм «Татнефть» проектларын хуплаячак, инвесторларга уңайлы шартлар булачак», – диде Касыйм-Җомарт Токаев.

Татарстан Президенты яңа Премьер-министр Алихан Смаилов белән дә очрашты. «Казахстан – Татарстанның алдынгы чит ил хезмәттәшләренең берсе», – диде Рөстәм Миңнеханов очрашуда. Ул Кустанайда чуен кою һәм «КамАЗ» машиналары өчен җиһазлар җитештерү буенча заводлар төзелүен дә искәртте. Караганда өлкәсендә «Татнефть» ГАҖ һәм «Аллюр» компанияләр төркеменең шиннар җитештерү буенча уртак предприятиесе төзелә башлады. Татарстан Президенты фикеренчә, энергетика, сәнәгать, газ-мотор ягулыгы, авыл хуҗалыгы, нефть химиясе юнәлешләрендә хезмәттәшлек итү мөмкинлеге зур. Алихан Смаилов әйтүенчә, якын киләчәктә ике арадагы товар әйләнешен бер миллиард долларга кадәр арттыра алабыз.

Казахстанга эшлекле сәфәр барышында Рөстәм Миңнеханов «КамАЗ» оешмасының Акмолла автоүзәгендә дә булды. Республика җитәкчесе автоүзәкне, складны һәм махсус техника җыю үзәген карады. Узган елның тугыз аенда Казахстанда яңа йөк автомобильләре базарының 42 процентын (1068 берәмлек) «КамАЗ» машиналары тәшкил иткән.

ХЫЯЛЛАНЫГЫЗ ҺӘМ МАКСАТЛАРЫГЫЗГА ИРЕШЕГЕЗ!

Татарстан Президенты РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВның Россия Студентлар көне уңаеннан котлавы

Россиядә тәүге университет пәйда булганнан бирле Татьяна көне дип дә аталып йөртелүче бу бәйрәм хаклы төстә студентлар дуслыгы-туганлыгы билгесе булып тора. Татарстанда әлеге бәйрәм 140 меңнән артыграк студентны берләштерә. Без үз яшьләребез – күпкә ирешүгә омтылучы, тормышта актив позициядә торучы талантлы егет-кызларыбыз белән горурланабыз. Студентларның мәгарифтә генә түгел, фән, спорт, сәнгать өлкәсендәге уңышлары да зур ихтирам-хөрмәт уята.

Бүген Татарстан белем бирү һәм югары квалификацияле кадрлар әзерләү өлкәсендә күп кенә юнәлешләр буенча алдынгы сафларда бара. Студентлар һәм яшь белгечләребез Россия күләмендәге генә түгел, халыкара бәйгеләр һәм олимпиадаларда да зур уңышларга ирешеп килә. Узган елда республикадан берьюлы биш вуз «Приоритет – 2030» программасына кертелде. Шулай ук 2021 елда Россиядә иң яхшы дип танылган студентның да Татарстаннан булуы белән горурланабыз.

Соңгы еллар, пандемия сәбәпле, барыбыз өчен дә ныклыкка сынауга әйләнде. Әмма бу кыенлыклар, безне чыныктырып, үз көчебезгә ышанычны өстәде, иң зур кыенлыкларны да җиңеп чыга алуыбызны күрсәтте.

Кадерле студентлар! Сер түгел: гыйлем эстәү сабырлык, тәртиплелек, киләчәккә җитди, җаваплы мөнәсәбәт таләп итә. Вузларыгыздагы фәнни мәктәпләрнең иң яхшы традицияләрен дәвам итәчәгегезгә, илебезнең үсешенә лаеклы өлеш кертәчәгегезгә чын күңелдән ышанам. Студент еллары тормышыгызда иң якты, иң нык истә калырлык чорга әйләнсен! Кыюрак һәм тәвәккәлрәк булыгыз, рәхәтләнеп иҗат итегез, хыялланыгыз һәм максатларыгызга ирешегез! Бәйрәм белән!

Истәлеккә калсын

МӘДӘНИ МИРАСНЫ САКЛАУ КОМИТЕТЫ УЗГАН ЕЛГА НӘТИҖӘ ЯСАДЫ

Сакларга, торгызырга, киләчәккә калдырырга. Татарстанның мәдәни мирас объектларын саклау буенча комитет үз эшчәнлеген шул сүзләргә таянып башкара. Узган ел нәрсәгә ирешкәннәр? Мәдәни мирас саналган корылмалар артканмы, киресенчәме? Комитет еллык хисап тотты.

Мәгълүм булганча, быел ил күләмендә Россия халыклары мәдәни мирасы елы дип игълан ителде. Комитет җитәкчесе Иван Гущин әйтүенчә, шушы тармакта көн-төн эшләгәннәр өчен бу күптән көтелгән вакыйга иде. Игътибар белән бергә, җаваплылык артуын да аңлыйбыз, диләр алар.

Санлы мәгълүматларга килгәндә, Татарстандагы 1687 мәдәни мирас объекты Россия халыкларының мәдәни мирас объектлары бердәм дәүләт реестрына кертелгән (былтыр 1663 иде). Аларның 447се – федераль әһәмияттәге, 896сы – төбәк әһәмиятендәге, 344е – җирле әһәмияттәге корылмалар. Ел дәвамында моңа кадәр билгеле булмаган 14 археологик һәйкәлгә тап булганнар.

Комитет башлыгы чыгышыннан аңлашылганча, инвентарьлаштыру эше дә дәвам итә. Иван Гущин сүзләренчә, узган ел 21642 күчемсез милек объекты (җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары) өйрәнелгән һәм алар мәдәни мирас объектларына керү-кермәү буенча анализланган.

Иван Гущин әйтүенчә, былтыр 47 физик һәм юридик зат мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә закон бозган өчен административ җаваплылыкка тартылган, хокук бозулар турында 65 беркетмә төзелгән. Шикаять сәбәпләренең күпчелеге мәдәни мирас корылмаларын тиешле хәлдә карап тотмау һәм рөхсәт ителмәгән урыннарда эш алып баруга бәйле. Бу рәвешле эш итүчеләргә салынган штраф күләме якынча 3,5 млн сумга җиткән.

Төзекләндерү эшләренә килгәндә, узган ел комитет көче белән Казандагы Чекмаревлар йортын, Алабугадагы Иван Шишкин музей-йортын, Әгерҗедәге Мөхәммәтҗан Әхмәтҗанов йортын реставрацияләү эшләре тәмамлануын санап үттеләр.

Быелга да эш җитәрлек әле. Әйтик, Казанның Пискуновлар йорты, Сапогульцев утары, «Мәрҗани» мәдрәсәсе биналарында ремонт-реставрация эшләре көтелә.

Татарстанда игълан ителгән Цифрлаштыру елы уңаеннан да ике төп юнәлештә эшне дәвам итәргә җыена комитет белгечләре. Берсе – «Дәүләт хезмәтләре»н электрон рәвешкә күчерү. Икенчесе – мәдәни мирас объектларын саклауда замана технологияләрен куллану. Бу очракта сүз корылманың электрон паспортларын булдыру турында бара.

«Сакларга, торгызырга, киләчәккә тапшырырга» дигән сүзләрне тормышка ашыру өчен, билгеле, белемле хезмәткәрләр кирәк. Кадрлар кытлыгы мәсьәләсенең кискен торуы бер генә тапкыр телгә алынмады утырышта. КГАСУ ректоры Рәшит Низамов бу проблеманы чишү юлларының берничәсен атап үтте. Иң элек, бакалавр юнәлеше буенча укучы реставраторлар санын арттыру зарур. Ил күләмендә дә андый белгечләрне әзерли торган уку йортлары 13 кенә икән. Татарстанда 8 музей-тыюлык, ЮНЕСКО карамагындагы 3 объект бар. Район җирлекләрендә дә белгечләр җитәрлек дип булмыйдыр. Бу җәһәттән булачак студентларны максатчан укытуны кулай дип саныйлар. Тагын бер юл – магистратура юнәлешендә архитектура һәм инженерлык белгечлеге алганнарны укыту.

Хәтерләү, хатирә саклау турында еш сөйләделәр утырышта. Әйтик, вице-премьер Ләйлә Фазлыева Татарстан үсеше өчен саллы өлеш керткәннәр турында истә тотарга өндәде. Моның өчен цифрлы хәтер китабын булдыру ярап куяр иде. «Бик авыр хезмәт булыр ул. Әмма безгә моны эшләргә, бу хакта мәгълүматны балаларыбызга тапшырырга кирәк», – диде.

3 НЧЕ ИКМӘК ПЕШЕРҮ ЗАВОДЫ ЭШЧЕЛӘРЕ:

«БУ ВАКЫЙГА БЕЗНЕ КӨЧЛЕРӘК ИТТЕ»

Узган атнада Казанның данлыклы 3 нче икмәк пешерү заводы тирәсендә зур шау-шу кузгалды. 80 елдан артык тарихы булган, ярты шәһәр халкын һәм башкалага якын булган районнарны ипиле иткән заводны ябалар икән, дигән хәбәрне эшчеләр генә түгел, сатып алучылар да аяз көнне яшен суккандай кабул итте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Эшчеләр, дәррәү кубарылып, хезмәт урыннарын саклап калу өчен көрәште. Араларында хәтта: «Кирәк икән, завод өчен гомеребезне дә бирергә әзербез», – диючеләр дә булды. Шөкер, аларның җан әрнүен республика җитәкчелеге ишетте. Атна ахырында: «Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча заводны үз урынында калдыралар икән», – дигән хәбәр алдык. Дүшәмбе исә без эшчеләрнең хәлләрен белешеп кайттык.

Кычытмаган җирне нигә кашырга?

Бүлек мөдире Инзар Җиһангиров безне заводка керү юлында каршы алды. Узган атнада журналистлар тарафыннан игътибар зур булганлыктан, территориягә керү белән авырлыклар килеп чыккан икән. Шуңа күрә алга таба сөйләшүне дә завод ишек төбендә дәвам иттек.

Яңа танышыбыз әйтүенчә, заводны ябарга уйлыйлар икән, дигән сүзләр халык арасында күптән таралган. Ә соңгы атналарда мондый хәбәрләр ешайган, һәр яклап килүче бер төрле эчтәлектәге хәбәрләр саны арткан. Җитмәсә, «Ак барс» холдингыннан 1 марттан заказларны «Күмәч-кондитер комбинаты»на (БКК) җибәрү турында хат та килеп төшкән… Эшчеләр әйтүенчә, холдинг, бу территорияне сатып, әлеге урынга күпкатлы йортлар салмакчы булган. Ә эшчәнлекнең бер өлешен «Күмәч-кондитер комбинаты» мәйданына күчерергә теләгән. Аңлатып китик: оешмаларның икесе дә «Ак барс» холдинг компаниясенә карый.

Шулай итеп эшчеләр, эшсез калу ихтималын чамалап, узган атна башында дәррәү кузгалган.

– Әгәр бу хәбәр чынга аша калса, кешеләр гаиләләре белән эшсез калачак иде, – ди Инзар Җиһангиров. – Бездә ире, хатыны, балалары белән бергә эшләүчеләр шактый. Күбесенең ипотека, кредит түлисе бар. Хезмәт елларын шушы заводта башлап, биредән лаеклы ялга китүчеләр дә юк түгел. Ә комбинатка нибары 250 кешене генә алып китәчәкләр иде. Анда технологлар, диспетчерлар, пешекчеләр, йөк ташучылар җитми. Менә шул белгечләр китәргә тиеш булды. Ә калганнарга нишләргә? Эшсез калабыз бит, дип еладылар.

3 нче икмәк пешерү заводы – Татарстанның иң эре предприятиеләренең берсе. Биредә 1400 кеше эшли. Ул тәүлегенә 60 тонна икмәк пешерә, 3,5 тонна коры кондитер ризыгы, 2,5 тонна чәкчәк һәм 0,5 тонна торт әзерли. Казанның икмәк продукциясе базарының 52 проценты әлеге оешмага туры килә. Базарның калган өлешен БКК һәм 2 нче икмәк пешерү заводы бүлешә. Боларга өстәп, 3 нче икмәк пешерү заводының ризыклары башкалага якын булган районнардагы кибетләргә дә таратыла. Барысы бергә 73 ноктада сатыла ипиләре. Узган атна эшчеләр өчен авыр булса да, эшләре бер генә көнгә дә тукталмаган.

– Киресенчә, берләшеп, тагын да тырышыбрак эшли башладык. Халыкка бу турыда әйтергә дә кирәкмәде, бу мөнәсәбәт сизелеп, күренеп торды. Безнең коллектив бердәм икән, дип горурланып әйтә алам. Бер-беребезгә ярдәм кулы сузып эш йөрттек. Хәтта үзем өчен дә ачыш булды бу, – диде әңгәмәдәшебез. – Завод файдага эшли. Салымнарны түләп барабыз. Хезмәт хаклары алуда бервакытта да тоткарлыклар булмады. Төрле белгеч төрлечә хезмәт хакы ала. Төп белгечләрнең уртача хезмәт хаклары 25–30 мең сум тирәседер. 13, 14 нче түләүләр, социаль түләүләр – барысы да бар. Эшләгән вакытта авырлыклар була инде ул. Ләкин алар барысы да – хәл ителә торган авырлыклар. Җитәкчебез Джавидин Кафаров – бик төпле, акыллы кеше. Беренче чиратта халык мәнфәгатен кайгырта. Шулай булгач, нигә кирәк заводны ябу?

«Аяк чалуларга әзербез»

Әлеге вакыйгалар Татарстан белән генә чикләнмәде. Заводта эшләүчеләр Россия Президенты Владимир Путин исеменә петиция дә язды. Аңа кул куючылар саны дүшәмбе иртәсенә 11 меңнән артып киткән иде. Һәм атна ахырына эшчеләрнең күңеленә җылылык биргән яңа хәбәр килеп иреште: заводта үзгәреш булмаячак.

– Җомга көнне холдингтан шалтыратып, барысы да элеккечә калачак, дип сөендерделәр. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка зур рәхмәт. Халык җиңел сулап куйды. Без бик шат, дип әйтү генә аз, – диде безнең белән очрашкан Инзар әфәнде.

Аның белән сөйләшкәч, завод территориясендәге ипи кибетенә дә кереп чыктык. Анда да сатып алучылар шактый иде.

– Мин күрше йортта гына яшим. Үзем дә, балаларым да гел шушы кибеткә генә йөрибез. Бик яратабыз продукцияләрен, – диде сатып алучы Валя ханым. – Узган атнадагы хәлләрне бик борчылып күзәттек. Каян килеп чыкты бу галәмәт? Ничәмә ничә еллар эшләгән заводның ишегенә менә шулай йозак элеп куеп була димени? Күпме кеше эшли бит анда. Алар нишләргә тиеш булды икән соң? Инде барысы да шулай узып китсә ярар иде, дип телибез.

Завод бүген дә ничек эшләгән, эшчәнлеген шул килеш дәвам иттерә. Тагын да тырышыбрак хезмәт куябыз әле, ди Инзар Җиһангиров.

– Алга таба да ниндидер авырлыклар, аяк чалырга тырышулар булыр әле, дип уйлыйбыз. Ләкин без аңа әзер. Бу вакыйгалар безне тагын да көчлерәк итте, коллективны берләштерде. Бездә халык, авырлык килгәндә, бер йодрык булып туплана ала икән. Бездә профсоюз беткән иде. Аны хәзер закон буенча кабаттан оештырабыз. Ул да киләчәктә ярдәм итәр дип өметләнәбез, – диде ул.

Икмәк ашаучылар кими

Узган атнада бу уңайдан без Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының да фикерен белешкән идек. Матбугат үзәге юллаган рәсми хаттан аңлашылганча, Россия икмәк базары ел саен кечерәя. Соңгы ун елда гына да бер россияле кулланган икмәк күләме 66 килограммнан 49 килограммга кадәр кимегән. Ягъни бер кеше 26 процентка кимрәк ипи ашый башлаган.

Гомуми базардагы хәлләр ипи пешерү заводына да йогынты ясамый калмый, әлбәттә. 2011 елдан башлап 3 нче икмәк пешерү заводы җитештергән продукция күләме 36 процентка кимегән. (Елына 32 мең тоннадан 20,5 тоннага калган.) Шуңа охшаш хәл «Күмәч-кондитер комбинаты»нда да күзәтелгән. Биредә җитештерү 3 процентка кимегән.

2020–2021 елларда 3 нче икмәк пешерү заводы мәйданында төрле инвестицион проектларны тормышка ашыру буенча сөйләшүләр алып барылды. Монда, аерым алганда, сүз ипи продукциясен туңдырып сату турында бара иде. Ләкин моның өчен акча күп кирәк булганлыктан һәм көндәшлек зур булу сәбәпле, проект тормышка ашмый калган.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Рәсми документ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА МИНИМАЛЬ ЭШ ХАКЫ ТУРЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҺӨНӘР БЕРЛЕКЛӘРЕ ФЕДЕРАЦИЯСЕ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭШ БИРҮЧЕЛӘР БЕРЛӘШМӘЛӘРЕНЕҢ КООРДИНАЦИЯ СОВЕТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АРАСЫНДА КИЛЕШҮ

Казан ш., 24 декабрь, 2021 ел № 1100-С

«Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе» берлеге (алга таба – Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе) – Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе Уставы нигезендә эш итүче рәисе Кузьмичева Елена Ивановна йөзендә, Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең координация советы – Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләре координация советы турында нигезләмә нигезендә эш итүче рәисе Лаврентьев Александр Петрович йөзендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Конституциясе, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры Песошин Алексей Валерьевич йөзендә, алга таба Яклар дип атала, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 133^1 статьясы, «Татарстан Республикасында социаль партнерлык органнары турында» 2004 елның 26 июлендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, түбәндәгеләр турында бу Килешүне төзеде:

1 статья

1. Татарстан Республикасы территориясендә эшләүче хезмәткәрләр өчен, федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан финанслана торган оешмалардан тыш, 2022 елның 1 гыйнварыннан аена 16,7 мең сум күләмендә минималь эш хакы билгеләнә.

Минималь хезмәт хакы 2021 елның II кварталы өчен Татарстан Республикасы буенча тулаем минималь кулланучы бюджетының 93,3 проценты күләмендә билгеләнгән һәм эш вакытының Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән айлык нормасын эшләгән һәм хезмәт нормаларын (хезмәт бурычларын) үтәгән хезмәткәргә тариф ставкасын (оклад) яисә тарифсыз система буенча хезмәт өчен түләүне, шулай ук өстәп түләүләрне, өстәмә түләүләрне, премияләр һәм башка түләүләрне үз эченә алган түләүләрнең минималь суммасын үз эченә ала, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 147, 151 – 154 статьялары нигезендә башкарыла торган түләүләрдән тыш.

2. Бу Килешүдә билгеләнгән Татарстан Республикасында минималь эш хакы күләмен Татарстан Республикасы икътисадының бюджеттан тыш секторлары оешмалары һәм юридик зат оештырмыйча, үз акчасы исәбеннән эшмәкәрлек эшчәнлеге алып баручы шәхси эшмәкәрләр тәэмин итә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр өчен минималь эш хакы «Хезмәткә түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы территориясендә эшләүче һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 133^1 статьясында билгеләнгән тәртиптә үзенә карата бу Килешү гамәлдә булган яки бу Килешү кагылган эш бирүче белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы хезмәткәрнең айлык эш хакы әлеге хезмәткәр шушы чорда эш вакыты нормасын тулысынча үтәгән һәм хезмәт нормаларын (хезмәт бурычлары) үтәгән шартларда, бу Килешүдә билгеләнгән минималь эш хакы күләменнән кимрәк була алмый.

5. Бу Килешүдә билгеләнгән минималь эш хакы күләме хезмәткә түләү буенча югарырак минималь гарантияләр билгеләүгә чикләү булып тормый.

6. Әлеге Килешүнең 1 пунктында күздә тотылган хезмәткәрләр өчен билгеләнгән минималь эш хакы күләмен Татарстан Республикасы минималь кулланучылар бюджеты зурлыгын бәясенә кадәр этаплап арттыру максатында («Татарстан Республикасында минималь кулланучылар бюджеты турында» 2008 елның 23 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясын гамәлгә ашыру кысаларында) минималь эш хакы күләмен арттыруның киләсе вакыты итеп 2023 елның 1 гыйнвары билгеләнә, ул 2022 елның II кварталына Татарстан Республикасы буенча гомумән алганда минималь кулланучылар бюджеты зурлыгының процент чагыштырмасында билгеләнә.

2 статья

Яклар бу Килешүнең тормышка ашуын тәэмин итү өчен:

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 133^1 статьясында билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара торган, бу Килешүне төзүдә катнашмаган эш бирүчеләрнең бу Килешүгә кушылуын тәэмин итү буенча чараларга күрә, шул исәптән бу Килешүгә кушылудан баш тарткан эш бирүче вәкилләре һәм бу эш бирүче хезмәткәрләрен берләштергән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы вәкилләре белән консультацияләрдә катнаша;

шушы чорда эш вакыты нормасын тулысынча үтәгән һәм хезмәт нормаларын (хезмәт бурычлары) үтәгән хезмәткәрнең айлык эш хакы күләмен бу Килешүдә билгеләнгән минималь эш хакы күләме дәрәҗәсендә хезмәткә түләү күләмнәрен билгеләү буенча чаралар күрә;

бу Килешүне үтәүгә мониторинг үткәрү һәм Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе һәм аның эшче төркеме утырышларында киңәшмә елга бер тапкыр аның нәтиҗәләрен карап тикшерә.

3 статья

1. Бу Килешү төзелгәннән соң Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы буларак, Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара торган һәм бу Килешүне төзүдә катнашмаган эш бирүчеләргә аңа кушылырга тәкъдим итә. Әлеге тәкъдим бу Килешүнең тексты белән бергә «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында рәсми төстә басылып чыгарга тиеш.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы бу Килешүне һәм аңа кушылырга тәкъдимнәрне бастырып чыгару турында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына хәбәр итә.

2. Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара торган эш бирүче, бу Килешүгә кушылу мөмкинлеге булмаган очракта, бу Килешүгә кушылу турында тәкъдим рәсми басылып чыкканнан соң 30 календарь көне эчендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына әлеге статьяның 2 пунктында билгеләнгән тәртиптә Килешүгә кушылудан нигезле язмача баш тарту тапшырмаган очракта әлеге Килешү күрсәтелгән тәкъдим рәсми басылып чыккан көннән башлап әлеге эш бирүчеләргә кагыла дип санала һәм алар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш. Баш тартуга бу эш бирүченең әлеге эш бирүче хезмәткәрләрен берләштергән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән консультацияләре беркетмәсе һәм бу Килешүнең 1 статьясындагы 1 пунктында күздә тотылган күләмгә кадәр хезмәткәрләрнең минималь эш хакын арттыру сроклары буенча тәкъдимнәр кушып бирелергә тиеш.

Эш бирүче хезмәткәрләре нинди дә булса башлангыч һөнәр берлеге оешмаларына берләштерелмәгән яки гамәлдәге башлангыч һөнәр берлеге оешмаларының берсе дә әлеге эш бирүче хезмәткәрләренең яртысыннан артыграгын берләштермәгән һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексында билгеләнгән тәртиптә әлеге эш бирүченең барлык хезмәткәрләре мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә вәкаләтле булмаган очракларда, баш тартуга эш бирүченең Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 31 статьясында билгеләнгән тәртиптә сайланулы башка вәкиллекле хезмәткәрләр органы (вәкил) белән консультацияләр беркетмәсе һәм хезмәткәрләрнең минималь эш хакын югарыда күрсәтеп үтелгән Килешүнең 1 статьясындагы 1 пунктта күздә тотылган күләмгә кадәр арттыру сроклары буенча тәкъдимнәр кушып бирелергә тиеш.

3. Эш бирүчеләр – Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы, әлеге Килешүгә кушылу турында тәкъдимнәрне рәсми басылып чыккан көненнән соң төзегән һәм эшчәнлеген башлаган юридик затлар, юридик зат оештырмыйча шәхси эшмәкәрләр, әлеге Килешүгә кушылу мөмкинлеге булмаган очракта Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, дәүләт теркәвенә алынганнан соң 30 календарь көн эчендә, әлеге статьяның 2 пунктында каралган документлар белән нигезле язмача баш тарту җибәрергә хокуклы.

Әлеге нигезле язмача баш тартуны тапшырмаган очракта, бу Килешү әлеге эш бирүчеләргә кагылган дип санала, һәм ул алар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш.

4. Эш бирүче бу Килешүгә кушылудан баш тарткан очракта Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы әлеге эш бирүче вәкилләрен, әлеге эш бирүче хезмәткәрләрен берләштергән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы вәкилләрен яисә әлеге эш бирүче хезмәткәрләренең башка вәкиллекле органы вәкилләрен Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе яклары вәкилләре катнашында консультацияләр үткәрү өчен чакыруга хокуклы.

Эш бирүче вәкилләре, башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы вәкилләре яки эш бирүче хезмәткәрләренең башка вәкиллекле органы вәкилләре һәм Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе вәкилләре бу консультацияләрдә катнашырга бурычлы.

5. Эш бирүчеләрнең югарыда күрсәтеп үтелгән Килешүгә кушылудан язмача баш тартуларының күчермәләре Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәт инспекциясенә җибәрелә.

4 статья

1. Бу Килешү шартларын үтәүне тикшерүдә тотуны турыдан-туры Яклар үзләре билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

2. Бу Килешүне үтәүне тикшерүдә тотканда, Яклар тиешле сорату алынганнан соң 30 календарь көне эчендә моның өчен кирәкле барлык мәгълүматларны бер-берсенә тапшырырга бурычлы.

5 статья

Бу Килешү Татарстан Республикасы икътисадының бюджеттан тыш секторы оешмаларына – Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара торган, бу Килешүне төзегән яки бу Килешүнең 3 статьясында билгеләнгән тәртиптә бу Килешүгә кушылган юридик һәм физик затларга, юридик зат оештырмаган шәхси эшмәкәрләргә кагыла.

6 статья

Әлеге Килешүнең шартлары Якларның үзара ризалыгы белән теләсә кайсы вакытта үзгәртелергә һәм тулыландырылырга мөмкин. Өстәмәләр һәм үзгәрешләр Килешү төзү өчен күздә тотылган тәртиптә кертелә һәм бу Килешү белән билгеләнгән минималь эш хакы күләмен киметә алмый.

7 статья

Бу Килешүне аңлауга һәм куллануга бәйле рәвешле яклар арасында килеп чыккан бәхәсләр үзара консультацияләр һәм сөйләшүләр юлы белән хәл ителә.

8 статья

1. Бу Килешү тексты түбәндәгеләргә җибәрелә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль районнар һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына, шулай ук билгеләнгән тәртиптә рәсми бастырып чыгаруга;

Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең координация советы тарафыннан – әлеге берләшмәләр составына керүче оешмаларга;

Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе тарафыннан – республика тармак һөнәр берлекләре органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре һөнәр берлекләре оешмаларының координация советларына, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары һөнәр берлекләренең тармак комитетларына (советларына), Татарстан Республикасы предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләренең һөнәр берлекләре оешмаларына.

2. Бу Килешү тексты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Якларның рәсми сайтларында урнаштырыла.

9 статья

Бу Килешү бердәй юридик көчкә ия булган өч нөсхәдә имзалана, һәр Як өчен бер нөсхә.

10 статья

Бу Килешү 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм Татарстан Республикасында минималь эш хакы турында яңа килешү үз көченә кергәнче гамәлдә була.

Якларның имзалары:

Татарстан Республикасы Премьер-министры	Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе Рәисе	Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең Координация советы рәисе
_______ А.В.Песошин	_____Е.И.Кузьмичева	____А.П.Лаврентьев

Эш бирүчеләргә Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе, Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең Координация советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында 2021 елның 24 декабрендәге Татарстан Республикасында минималь хезмәт хакы турындагы килешүгә кушылу хакында тәкъдим

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы һәм әлеге Килешүне төзүдә катнашмаган эш бирүчеләргә, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 133^1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе, Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең Координация советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында 2021 елның 24 декабрендәге Татарстан Республикасында минималь хезмәт хакы турындагы килешүгә кушылырга тәкъдим итә.

Килешү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында 2021 елның 24 декабрендә 324 номер белән теркәлгән.

Әгәр Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы эш бирүчеләр әлеге тәкъдим рәсми басылып чыккан көннән 30 (утыз) календарь көн эчендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына язма рәвештә югарыда күрсәтелгән Килешүгә кушылудан нигезле баш тарту тапшырмасалар, әлеге Килешү бу тәкъдим рәсми басылып чыккан көннән соң әлеге эш бирүчеләргә таратылган дип санала һәм алар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш.

Күрсәтелгән баш тартуга түбәндәгеләр теркәлергә тиеш:

әлеге эш бирүче хезмәткәрләрен берләштерүче беренчел һөнәр оешмасының сайланган органы белән эш бирүченең консультацияләре беркетмәсе;

югарыда күрсәтелгән Килешүнең 1 статьясындагы 1 пунктында каралган күләмгә кадәр хезмәткәрләрнең минималь хезмәт хакын арттыру сроклары буенча тәкъдимнәр. Шул ук вакытта Килешүнең 1 статьясындагы 6 пункты белән минималь хезмәт хакы күләмен арттыруның киләсе срогы 2023 елның 1 гыйнварыннан билгеләнә, дип каралган.

Эш бирүче хезмәткәрләре нинди дә булса беренчел һөнәр оешмаларына яки беренчел һөнәр оешмаларының берсе дә әлеге эш бирүченең яртысыннан артыгын берләштермәгән һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексы белән билгеләнгән тәртиптә әлеге эш бирүченең барлык хезмәткәрләренең мәнфәгатьләрен якларга вәкаләтле булмаган очракларда, күрсәтелгән баш тартуга эш бирүченең Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 31 статьясында билгеләнгән тәртиптә сайланган башка вәкиллекле орган (вәкил) белән консультацияләр беркетмәсе һәм югарыда күрсәтелгән Килешүнең 1 статьясындагы 1 пунктында каралган күләмгә кадәр хезмәткәрләрнең минималь хезмәт хакын арттыру сроклары буенча тәкъдимнәр беркетелергә тиеш.

Эш бирүче югарыда күрсәтелгән Килешүгә кушылудан баш тарткан очракта, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы әлеге эш бирүче вәкилләрен, әлеге эш бирүчене берләштерә торган беренчел һөнәр оешмасының сайланулы органы вәкилләрен яисә әлеге эш бирүче хезмәткәрләренең бүтән вәкиллекле органы вәкилләрен Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе яклар катнашында консультацияләр үткәрү өчен чакырырга хокуклы.

Эш бирүче вәкилләре, беренчел һөнәр оешмасының сайланган органы вәкилләре яки эш бирүче хезмәткәрләренең башка вәкиллекле органы вәкилләре һәм Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе вәкилләре әлеге консультацияләрдә катнашырга бурычлы.

Эш бирүчеләрнең әлеге Килешүгә кушылудан язмача баш тартулары күчермәләре Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәт инспекциясенә җибәрелә.

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры, Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясенең Хөкүмәт ягыннан координаторы
Э.Ә. Зарипова

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең технологик үсеш үзәге проект офисы баш эксперты **Миңнуллин** Рәшит Мәрдан улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары – «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе башлыгы **Хәлимов** Рөстәм Хәмис улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры ярдәмчесе – бүлек башлыгы **Андронов** Александр Николаевич Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе идарәсе башлыгы **Фадеев** Владимир Гелиевич Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Нефть һәм газ сәнәгате өлкәсендәге казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләве өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефтегазпереработка» идарәсе компрессор җайланмалары машинисты **Гайнуллин** Мәхмүт Мәүлет улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Заманча элемтә чараларын үстерү һәм камилләштерүдәге казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерциясез оешмасы генераль директоры киңәшчесе **Михайлов** Дмитрий Александровичка Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган элемтә һәм мәгълүмат хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге һәм татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» җәмәгать оешмасы (Иҗат берлеге) рәисе **Зәйдуллин** Ркаил Рафаил улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Эшендә ирешкән уңышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Төбәк автоматлаштырылган мәгълүмат-идарә системасы дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесенең юридик һәм оештыру-кадрлар эше бүлеге баш белгече **Березина** Вера Николаевна; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Эшләр идарәчесе урынбасары **Вәлиев** Альберт Мансур улы; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанслар һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе икътисад һәм финанслар бүлеге башлыгы **Дарьина** Эльза Әхмәдулла кызы; республиканың сайлау системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе аппаратының хокук бүлеге мөдире **Григорьева** Елена Борисовна; республикада куллану базары һәм хезмәт күрсәтүләр өлкәсен үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Казакова** Алсу Мәсхут кызы; законлылыкны ныгытуга, гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Колчин** Владимир Евгеньевич; халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары, актив иҗтимагый эшчәнлеге һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең психиатрия һәм медицина психологиясе кафедрасы мөдире **Менделевич** Владимир Давыдович; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «БЕРДӘМ РОССИЯ» бөтенроссия сәяси партиясе Төбәк башкарма комитетының Партиянең җирле бүлекчәләре эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге Татарстан төбәк бүлекчәсенең Чаллы җирле бүлекчәсе башкарма секретаре **Шуралева** Елена Леонидовна Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе **Яһудин** Шакир Шаяхмәт улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Спецавтотранс НК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Кудаяров** Наил Миргазиян улына, «Агро» җитештерү-коммерция фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Обухов** Андрей Сергеевичка, Казан шәһәренең «Хуҗалык-транспорт идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең автомобиль йөртүчесе **Смирнов** Олег Валерьевичка, «Алексеевскдорстрой» ачык акционерлык җәмгыятенең автомобиль йөртүчесе **Хәмидуллин** Мөнир Рияз улына, шәхси эшкуар «Курочкин Сергей Васильевич» автомобиль йөртүчесе-экспедиторы **Шәрәпов** Илшат Ришат улына **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ О НЕОБХОДИМОСТИ СОГЛАСОВАНИЯ ГРАНИЦ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Катиным Сергеем Вячеславовичем (аттестат 16-11-169, адрес: 420138, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 51Г, офис 1, тел.: (917) 850-99-44) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:170118:11, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань Приволжский район, СНТ «Волга ЗАО «Кварт», участок 160, выполняются кадастровые работы по уточнению местоположения границ и площади данного земельного участка. Заказчик: Валимухаметов Ленар Альфридович, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Ботаническая, д. 31, тел.: +79178810085.
Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится 5 марта 2022 г. в 9 часов 00 минут по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 51Г, офис 1.
Ознакомиться с проектом межевого плана и предъявить обоснованные возражения относительно местоположения границ земельного участка можно по адресу: 420138, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 51Г, офис 1 в течение 30 (тридцати) дней со дня выхода данного извещения в печать.
Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ: 16:50:170118:163, 16:50:170118:162, 16:50:170118:5, 16:50:000000:21046, расположены в Республике Татарстан, г. Казань, СНТ «Волга ЗАО Кварт», в границах кадастрового квартала 16:50:170118.
При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

Спорт

Кемнең кулында – шуның авызында?

Россиядән Олимпиадага барасы уенчылар исемлеге билгеле. Җыелма командага «Ак барс»тан ике хоккейчыны чакырдылар. Моннан тыш, төп составка Татарстанда туып-үскән тагын берничә егет эләкте. Хоккей җәмәгатьчелеге исә исемлекнең гадел булуына шик белдерә.

Хоккейчылар җиңү яулый икән, башка төрләрдә нәтиҗә нинди булса да, Олимпиада уңышлы санала. Алка сугучылар оттыра икән, башка спортчылар күпме медаль отса да, Кышкы Уеннарның нәтиҗәсе яхшы дип әйтеп булмый. Бәхәсле булса да, спорт сөючеләр арасында әнә шундый фикер киң таралган. Кирәк чакта, спорт түрәләре дә оста файдалана аннан. Әйтик, 4 ел элек узган Пхенчхан Олимпиадасыннан соң шулай булды. Быел да хоккейны сәясәтнең бер өлеше итеп күрсәтергә омтылучылар юк түгел. Әйтик, җыелма команданың Пекинга барасы составын якшәмбе көнне Беренче каналда чыгучы «Время» тапшыруының ахырында игълан иттеләр.

«Ак барс»тан җыелма командага капкачы Тимур Билалов белән һөҗүмче Дмитрий Воронков чакырылды. Кандидатлар арасында Артем Галимов та бар иде, әмма ул төп составка эләкмәде. Хәер, 23 яшьлек һөҗүмченең Пекинга бармаячагын әле узган атнада ук чамаларга мөмкин иде. Чөнки әле әзерлек җыены башланганчы ук Галимовның команда белән шөгыльләнергә теләмәве турында хәбәр таралды. Әлбәттә, бу сүзләрне тиз арада кире кактылар, Артем исә Мәскәүгә юл тотты. Әмма ахыр чиктә төп составка барыбер эләкмәде. Төтен утсыз чыкмаган, димәк. Бәлки, егет моның шулай буласын алдан ук фаразлагандыр? Тренерлар уенчыларны сайлаганда егетнең бу кыланмышын исәпкә алган булырга мөмкинме? Сүз уңаеннан, «Время» тапшыруында башта Артемның командага запас уенчы буларак чакырылуын әйттеләр, ә берничә минуттан Пекинга ул түгел, ә «Салават Юлаев»тан Александр Кадейкин барасын җиткерделәр.

«Ак барс»ның ике уенчысыннан тыш, җыелма команда составына Татарстан хоккеенда тәрбия алган тагын ике егет эләкте. Түбән Камада туып-үскән сакчы Дамир Шәрипҗанов хәзерге вакытта «Авангард»та уйный. Бөгелмә егете Артур Каюмов исә «Локомотив»та чыгыш ясый.

Аның каравы КХЛдагы иң яхшы уенчылар сафына кергән, иң күп алка кертүчеләр арасында дүртенче урында баручы Антон Бурдасов Пекиндагы ярышны читтән генә күзәтәчәк. Лиганың иң нәтиҗәле бомбардирлары исемлегендә икенче урында баручы Андрей Кузьменко – запас уенчылар исемлегендә. КХЛда иң шәп уенчылар сафында йөрүче Дамир Җәгъфәров («Торпедо») та, узган ел Гагарин Кубогының иң файдалы уенчы булып танылган Сергей Толчинский да («Авангард»), Көнчыгыш Конференциядә беренче урында баручы «Трактор»дан Никита Тертышный да бармый Пекинга.

Составның нинди мантыйк белән тупланганын тренерлар белә. Җыелма команда белән исә ЦСКАга якын кешеләр идарә итә. Шуңа күрә исемлектә Мәскәү клубыннан берьюлы 7 уенчы булу гаҗәп тә түгел. Хуш, алар яхшы уенчы булырга мөмкин. Әмма тагын да яхшырак саналган һәм моны саннар белән раслаган хоккейчылар командага чакырылмады.

Россия җыелма командасы составы

Капкачылар: Тимур Билалов («Ак барс»), Александр Самонов (СКА), Иван Федотов (ЦСКА).

Сакчылар: Александр Никишин («Спартак»), Вячеслав Войнов («Динамо», Мәскәү), Александр Елесин («Локомотив»), Артём Минулин, Егор Яковлев (икесе дә – «Металлург»тан), Никита Нестеров (ЦСКА), Сергей Телегин («Трактор»), Дамир Шәрипҗанов («Авангард»).

Һөҗүмчеләр: Сергей Андронов, Михаил Григоренко, Павел Карнаухов, Сергей Плотников, Антон Слепышев (барысы да – ЦСКАдан), Никита Гусев, Кирилл Марченко (икесе дә – СКАдан), Вадим Шипачёв («Динамо», Мәскәү), Дмитрий Воронков («Ак барс»), Артур Каюмов, Артём Анисимов (икесе дә – «Локомотив»тан), Андрей Чибисов («Металлург»), Кирилл Семёнов, Арсений Грицюк (икесе дә – «Авангард»тан).

Запас уенчылар: Дмитрий Шугаев («Северсталь»), Семён Чистяков («Авангард»), Александр Кадейкин («Салават Юлаев»), Станислав Галиев («Динамо», Мәскәү), Андрей Кузьменко (СКА), Владимир Ткачёв («Трактор»).

Илнар ХӨСНУЛЛИН

ЭШКӘ ЧАКЫРАЛАР

«Талспецстрой» компаниясенә, «Газпромнефть»нең Ямалдагы объектларында вахта ысулы белән эшләү өчен:

МАН 6х6 йөк бушаткычын йөртүчеләр кирәк.

- 60 көн эшләп, 30 көн ял.
- чиста хезмәт хакы аена – **120 мең сум;**
- Нягань шәһәрендәге җыелу пунктына бару-кайту (плацкарт вагонда) бушка;
- туклану, кием-салым бушка;
- медкомиссия узу каралган.

Телефоны:

8(982) 500-00-12

Реклама

БАЛДАН ТАТЛЫ БӘЙРӘМ

БЫЕЛ «БАЛАЛАР ПРЕМИЯСЕ»НӘ КЕМНӘР ЛАЕК БУЛДЫ?

Аларның телләре җырлап ачылган, күрәсең. Сәхнәгә дә тәпи киткәнче үк ашкынгандыр бу балалар. «Балалар премиясе» лауреатлары турында сүзебез.

Быел әлеге тамашаны икенче мәртәбә уздырдылар. Узган елгысыннан әллә ни аерылмады үзе. Хәер, оештыручылар да әллә ниләр вәгъдә итмәде.

– Шаккатырырга теләмибез, безнең ирешкән дәрәҗәбезне саклыйсыбыз килә. Режиссер буларак, бүгенге лауреатлар белән эшләү бик ошады миңа. Алар – чын профессионаллар, инде чыныгырга өлгергән егет һәм кызлар. Алар – Франция, Испания мода йортларындагы подиумнарда катнашкан балалар, халыкара һәм Россия күләмендә уздырылган бәйгеләрдә үзләрен күрсәтергә өлгергән кечкенә «йолдыз»лар, – диде проектның авторы һәм режиссеры Гөлназ Сәфәрова.

«Балалар премиясе»н «TMTV музыкаль премиясе»нең кече сеңлесе дип атыйлар. Лауреатлар атналар дәвамында «TMTV» телеканалында баручы «Балалы солянка» тапшыруында катнаша, «иң-иң»нәре исә «УНИКС»ны шау-гөр китерә. Кыскасы, монда да – традицион тәртипләр, яшь чикләве генә башка.

Концерт башланыр алдыннан сәхнә артын барлап чыктык. Балалар бик дулкынланадыр инде, дигән уйлар белән. Бик исләре китми иде аларның. Әти-әниләре күбрәк борчылгандыр. Ә балаларның эшләре күп – очрашу хөрмәтенә «ТикТок»ка видео төшерергә кирәк. Шулай да, премияне алып баручыларның йөзендә дулкынлану күренә иде. Шуларның берсе – Зәлия Зиннурова белән бераз аралашып та алдык:

– «Балалар премиясе»н икенче ел рәттән алып барам. Кызык монда. Бер-беребез белән дуслашып беттек инде. Дулкынланган чакта да бер-беребезне тынычландырабыз. Минем белән бергә алып баручылар сүзләрен онытсалар, мин ярдәмгә киләчәкмен. Чөнки сценарийны тулысынча ятлап бетердем бугай инде, – диде ул безгә. – Минем киләчәктә әтием (алып баручы Зөлфәт Зиннуров турында сүз бара. – **Ред.**) кебек буласым килә. Менә шомара торам.

«Ришат абый миңа охшаган: ул да, мин дә өйләнмәгән»

Концертның үзенә килгәндә, ярты сәгать дәвам иткән «кызыл келәм» белән башланып китте ул. Һәр катнашучыны бер генә «регалия»сен дә төшереп калдырмыйча сәхнәгә дәштеләр, озак итеп кул чаптырдылар. Бар икән уңган балалар, дип утырырлык булды. Ул кечкенә кызчыкларны күрсәгез! Нәкъ курчак ясаганнар иде үзләреннән.

«Балалы солянка»ны хәтерлисездер инде? Танылган җырчылар һәм аларның балалары чыгыш ясый иде анда. Ә «Балалар премиясе»ндә катнашу өчен җырчы баласы булу төп шарт түгел. Биредә танылган җырчылар, сәләтле балалар белән «парлашып», үз «хит»ларын башкарды. Дөресен әйтик, кайбер чыгышлар сорау тудырды. Әйтик, кара-каршы басып, «яратмадың, мине сөймәдең» дип җырлашу ни дәрәҗәдә урынлы булды икән? Балалар өчен яңа җырлар язылмаганны аңладык инде, ләкин башка эчтәлектәге җырлар җитәрлек бит. Концерт буеннан-буена шундый җырлардан торган икән дип уйлый күрмәгез. Татар халык җырлары, ретро җырлар бик күп яңгырады. Кечкенә калфаклы кечкенә кызларны аеруча нык алкышладылар. Әминә Әхмәтҗанова «Ашхабат» җырын сайлаган. «Аны Әлфия апа Авзалова шундый матур итеп башкарган! Мин дә кызыктым, әнием һәм укытучым белән киңәшләшеп, бүген шул җырны башкарырга булдым», – диде ул безгә.

Ә иң күп алкышлар Камил Бах чыгышыннан соң яңгырады. Бәһаветдиновлар гаиләсе халык уен кораллары белән еш кына чыгыш ясый, ә монда Камил әллә ничә инструментка берүзе хуҗа иде.

Тамашачы мәхәббәтен тагын бер егет – Аслан Миргаязов та яулады. Икенче ел рәттән бит! Өлкән «коллега»лары – Рамил Шәрәповка алмаш үсә. Күп сөйләшә, аның: «Ришат абый миңа охшаган: ул да, мин дә өйләнмәгән», – дип, Ришат Төхвәтуллинны сәхнәгә дәшүе шулкадәр чын күңелдән яңгырады.

Ә Ришат Төхвәтуллин үз лейблының иң яшь җырчысы Камал (Камил Вәлиев) белән чыгыш ясады. Алар кичәнең махсус кунаклары иде. Соңыннан без аның белән яшь «йолдыз»лар турында сөйләштек.

– Киләчәкне барлауны балалардан башларга кирәк. Аларны чыныктыру, репертуарларын барлау, гомумән, нинди мохиттә үсүләрен кайгырту – безнең бурыч. Бәлки, алар эстрада юлын сайламас та. Ләкин алар биредә тормышка да өйрәнә бит. Мондый проектларда алар таныша, дуслаша, аралаша. Бала үз алдына максат куярга өйрәнә, – диде ул безгә. – Тамашачы белә инде: без яшь талантлы егет – Камал белән шактый уңышлы эшләп киләбез. Вокал ягын да, репертуар ягын да кайгыртабыз. Әле менә Казанда биш көн буе концерт куйдык, Камал һәркайсында чыгыш ясады. Кая гына барсак та, аны көтеп алалар. Миңа калса, үз яшенә күрә ул шактый уңышларга иреште. Камал үсә, инде тавышында үзгәрешләр барлыкка килә башлады. Шушы чорны матур гына, тавышына зыян китермичә кичереп, тагын да зуррак үрләр яуларга язсын, – диде Ришат.

«БАЛАЛАР ПРЕМИЯСЕ» ЛАУРЕАТЛАРЫ

Азалия Яфясова, Айза, Алия Төхвәтуллина, Әминә һәм Мәдинә Рәсуловалар, Аслан Миргаязов, Җәмилә Әсәдуллина, Милина Хәйруллина, Наилә Славина, Раяна Ибәтуллина, Элина Чеботарева, Ясминә Гарипова, Әминә Әхмәтҗанова, Сафинә Мингазова, «Веснушки» шоу-төркеме, «SUPER KIDS» төркеме, «Алтын» курайчылар ансамбле, Rayana Magic.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ЯШЬ ФЕЛЬДШЕР:

«АВЫЛГА КАЙТУЫМА ӘБИ-БАБАЙЛАР, ЕЛАП, РӘХМӘТ ӘЙТТЕ»

Без бер төрле уйлыйбыз, әмма язмыш дигәннәре башкасын тәгаенләп куя. Саба кызы Инзилә Зәкиҗанованың да тормышы көтелмәгән борылышларга бай булган. 22 яшендә күпләр өчен иң кирәкле кешегә, зарыгып көткән берәвенә әйләнә дә куя ул. Инзилә Елыш авылында фельдшер булып эшли.

– Медицина юлыннан китү балачак хыялым, димәс идем. Бу турыда күбрәк әбием хыяллангандыр дип уйлыйм. Ул мине үзе генә үстерде. «Мин картайгач, чирләсәм, дәваларсың мине, кая гына барсаң да, кирәкле һөнәр бит», – дия иде ул миңа. Әбием сүзенә каршы килә алмадым. Мине үстерергә ярдәм иткән башка туганнарым да бу фикерне хуплады. Аларның ярдәме, терәге белән Казан медицина көллиятенә укырга кердем, – дип сөйли Инзилә.

Көллияттә 32 кеше укыганнар. Берсе дә авылга кайтып эшләргә ашкынмаган, әлбәттә, бу хакта уйлап та бирмәгән.

Язмышның тагын бер шуклыгы булгандыр инде: Инзилә икенче курста укыган чакта оныгын ак халатлы шәфкать иясе итеп күрергә теләгән әбисе үлеп киткән.

– Авылга кайтып эшләү минем өчен көтелмәгән вакыйга булды. Шәһәрдә укыганда, барыбыз да алдагы тормышын Казанда күрә бит, – ди Инзилә. – Монда эшләрбез, яшәрбез, дип ниятләмәдек түгел. Без теләгәнчә генә булмый шул, димәк, миңа шулай язгандыр, дим. Авылга кайтып эшләргә туры килсә дә, мин үз хезмәтемне яратам, дәва эзләп килгән әби-бабайларымны да үз итәм. Мин кайткач, елап, рәхмәт әйтүчеләр дә булды.

Эш урынына кайтып урнашкач, Инзиләнең дә күзләре яшьләнмәгән түгелдер. Ник дигәндә, 4 ел фельдшерсыз торган авылдагы фельдшер-акушерлык пункты бик аяныч хәлдә булган.

– Мин эшкә кайтып урнашкандагы хәлен искә төшерү дә куркыныч инде хәзер. Шактый тырышырга туры килде. Хәтта тонометрны да үзем сатып алдым,

мөрәҗәгать белән килгән әби-бабайларның хәлен гел тикшереп торырга кирәк бит. 4 ай эшләгәннән соң, су ялгап киттеләр, моңа кадәр су да кермәгән иде, – ди Инзилә. – Авылга кайткач, әтием, туганнарым ярдәме белән эшләп китә алдым. Аларга рәхмәт.

Эш шартларына җайлашып, саладагыларның үз кешесенә әйләнеп беткән инде фельдшер кыз. Күпләренә җылы сүз дә – дәва. Бу кагыйдәне дә тиз аңлаган. «Һөнәремнең иң авыр ягы – кешеләр белән эшләү. Төрлесендә төрле холык бит, кәефләренә карыйсың. Һәркайсына җайлашырга кирәк. Сүзнең дәвалау көче бар. Бервакыт бер әбекәй килде, зарланды-зарланды да: «Әй, кызым, рәхмәт, эчемдәгесен сиңа сөйләгәч, җиңел булып китте, авыртмый икән бер җирем дә», – дип, рәхмәтләр әйтеп кайтып китте. Даруга караганда кайчак сүз кирәгрәк тә», – ди Инзилә.

Юкны уйлап көенгәнче, барны уйлап сөен, диләрме? Инзилә Зәкиҗанова авыл тормышының уңай якларын барлый.

– Әлбәттә, алар бик күп. Эштән җылы өйгә кайту гына да ни тора! Рәхәтләнеп, үзең яраткан эшләрне башкарып йөрисең, – ди яшь фельдшер. – Рәсем ясарга яратам. Хәзер вакыт кына тими. Бәйләү курсларын алдым, буш вакытта үзем өчен баш киеме, шарф бәйлим. Ашарга пешерергә яратам.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7043 данә
Гомуми тираж – 18156 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 210

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+